СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06.03.2020 Әгерҗе шәһәре № 46-2

2020 елга Әгерҗе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымтадагы 2020 елга Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына федераль законнар нигезендә 2020 елга «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) тормышка ашыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча Даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе В.В. МАКАРОВ

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Советы карары белән
«06» март 2020 № 46-2

2020 елга
«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен
ХОСУСЫЙЛАШТЫРУНЫҢ ФАРАЗ ПЛАНЫ (ПРОГРАММАСЫ)

I өлеш. 2020 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыру бурычлары

2020 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) (алга таба – хосусыйлаштыруның фараз планы) «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендага ала торган мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2014 елның 13 октябрендәге 35-1 номерлы карары белән расланган «Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында Нигезләмә» нигезендә эшләнде.

Муниципаль милек белән идарә итүнең базар икътисады шартларында формалаша торган система өлеше буларак, 2020 елда муниципаль милекне хосусыйлаштыруның төп бурычлары булып «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары функцияләрен һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган муниципаль милекне хосусыйлаштыру исәбенә муниципаль милек структурасын оптимальләштерү, шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы федераль закон, «Дәүләт яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендага ала торган мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен тормышка ашыру тора.

2020 елда хосусыйлаштыруның төп максатлары булып тора:

- муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырудан район бюджетына салым булмаган керемнәр кертүне тәэмин итү;

- бюджетның керем өлешен арттыру;
- мөлкәтне карап тотуга район бюджетыннан чыгымнарны киметү.

Хосусыйлаштыру процессы нәтиҗәсендә “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге икътисадында структур үзгәрешләр көтелми, чөнки хосусыйлаштыру өчен тәкъдим ителгән торак булмаган бинада милекче алышынганда муниципаль берәмлектәге икътисади вәзгыяткә сизелерлек йогынты ясарга сәләтле производство булдырылмый.

Хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) нигезендә сатуга планлаштырылган барлык объектларның якынча бәясе базар бәясен үткәрү юлы белән төгәлләштерелергә тиеш.

2020 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган мөлкәт исемлеге муниципаль милек структурасын алга таба оптимальләштерүне исәпкә алып тулыландырылырга мөмкин.

II өлеш. 2020 елда аны хосусыйлаштыру планлаштырылган Татарстан Республикасы "Әгерҗе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәте

| № | объект | адрес | Хосусыйлаштыру ысулы | реализациянең фаразланган вакыты | искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | MITSUBISHI LANCER автомобиле 1.6, иден. № (VIN) JMBSNCS3A7U004581, көмеш төсендә | МБУК Әгерҗе ЦКС карамагында | ачык аукцион | 2 квартал | Билгеләнеше буенча файдаланылмый |
| 2 | Торак булмаган бина 1 катлы. | Татарстан Республикасы , Әгерҗе ш, Заводская ур. 31Г | ачык аукцион | 3 квартал | Билгеләнеше буенча файдаланылмый |
| 3 | ТО пункты, 1 катлы. | Республика Татарстан Әгерҗе ш, Заводская ур. 31Г | ачык аукцион | 3 квартал | Билгеләнеше буенча файдаланылмый |